**ГЛАВА АЛЬДЕРМЫШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422711, Республика Татарстан, Высокогорский район
с. Альдермыш, ул. Хабибуллина, д.2

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ӨБРӘ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**
422711, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Әлдермеш авылы, Хабибуллина ур., 2

Тел./факс: +7(84365) 79-4-03, e-mail: Alder.Vsg@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**16 ноябрь 2021 ел** **№ 2**

**Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Биектау муниципаль районы Әлдермеш авыл җирлегенең Өбрә торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Биектау муниципаль районы Әлдермеш авыл җирлеге Уставының 22 статьясы һәм 2019 елның 24 октябрендәге 163 номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Әлдермеш авыл җирлеге составына керә торган торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» карары) нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Әлдермеш авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә:

1.1. 2021 елның 6 декабрендә 16.00 сәгатькә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Әлдермеш авыл җирлегенең Өбрә торак пунктында түбәндәге адрес буенча: Өбрэ ав., Союзная ур., 23 й. (С.Сайдашевнын музее янында);

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге сорауны расларга:

2.1. Өбрә торак пунктында: «2022 елда яшәү урыны буенча теркәлгән һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Әлдермеш авыл җирлегенең Өбрә торак пункты территориясендә даими яшәүче һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә, һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә, түбәндәге эшләрне башкаруга:

- поселок эчендәге юлларны карап тоту һәм ремонтлау;
- ясалма тигезсезлекләрне төзекләндерү Тукай ур.;

«ӘЙЕ» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда һәм җирлекнең рәсми сайтында кабул ителгән көненнән алып 10 көн эчендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Әлдермеш авыл җирлеге башлыгы Н.А.Усманов